Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Р.Р. Гайзатуллин,
А.Ю. Егоров,
А.В. Комисаров,
Э.Н. Хөснетдинов,
Е.А. Чекашов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ һәм $19^5$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш), № 47 (I өлеш); 2025, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $2^1$ статьяның 2 өлешендә:
а) $10^8$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$10^8$) Россия Федерациясе Шәхәр төзелеше кодексы нигезләмәләрен истә тотып, җирле үзидарә органнары тарафыннан җир кишәрлекләренә һәм (яисә) аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларына хокукы булганнар белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү, мондый шартнамә буенча хокукларны һәм бурычларны тапшыру тәртибен билгеләү;»;
б) түбәндәге эчтәлекле $10^{18}$ пункт өстәргә:
«$10^{18}$) Татарстан Республикасы төзелешкә рөхсәтләр реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибен, Татарстан Республикасы капиталь төзелеш объектларын кулланылышка тапшыруга рөхсәтләр реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибен билгеләү;»;

2) $19^{5}$ статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 66 статьясындагы $3^{1}$ өлешендә билгеләнгән очракта.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ һәм $19^5$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ һәм $19^5$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 4 августындагы 299-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 299-ФЗ номерлы Федераль закон) кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

299-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 66 статьясына территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул итү Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы тарафыннан кабул ителгән очракларның исемлеген киңәйтү буенча үзгәрешләр кертелде. Мәсәлән, 2026 елның 4 августыннан башлап Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны аңа федераль милектәге җир кишәрлекләре, башка күчемсез милек объектлары белән идарә итү һәм эш итү вәкаләтләре тапшырылган очракта кабул итәргә хокуклы. Бу очракта мондый карарны кабул иткәндә федераль башкарма хакимият органнары белән килештерү таләп итми.

Моннан тыш, 299-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 70 статьясына да үзгәрешләр кертелде. Алар комплекслы үсеш территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларына хокук читләштерелгән (башкага бирелгән) очракта, мондый кишәрлек һәм (яисә) башка күчемсез милек объекты хуҗасының үз хокукларын килешү һәм (яисә) шартнамә нигезендә өченче затка тапшыру хокукына кагыла. Бу очракта мондый шартнамә төзү, шартнамә нигезендә хокукларны һәм бурычларны тапшыру тәртибе Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты белән билгеләнергә тиеш.

Шулай ук 299-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органы Россия Федерациясе субъектының төзелешкә рөхсәтләр реестрын һәм капиталь төзелеш объектларын кулланылышка тапшыруга рөхсәтләр реестрын булдыру һәм алып бару тәртибен билгеләргә тиеш (элек Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма органының мондый тәртипне билгеләү хокукы карала иде).

299-ФЗ номерлы Федераль законның күрсәтелгән нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатында «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы (алга таба – 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) Татарстан Республикасы Законының 2.1 статьясына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрен билгели торган үзгәрешләр һәм территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кабул итә торган очраклар исемлеген киңәйтүче үзгәрешләр кертелә.

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ һәм $19^5$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ һәм $19^5$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ һәм $19^5$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасында территорияләрне комплекслы үстерү проектларын гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 24 сентябрендәге 913 номерлы карарына үзгәрешләр кертү, шулай ук Татарстан Республикасының төзелешкә рөхсәтләр реестрын булдыру һәм алып бару тәртибен, Татарстан Республикасының капиталь төзелеш объектларын кулланышка кертүгә рөхсәтләр реестрын булдыру һәм алып бару тәртибен билгеләү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актын кабул итү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^{1}$ һәм $19^{5}$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^{1}$ һәм $19^{5}$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.